**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Ташлы-Ковали, ул. Центральная, 68

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ташлы Кавал авылы, Үзәк ур, 68

Тел./факс: +7(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**30 сентябрь 2020 ел.** **№ 4**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлеше, 2004 елның 28 июнендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 июлендәге 156 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсен раслау турындагы» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенең 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 16 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга торак урыны бирү.».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Хайбуллин